| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08.09.2025 п.г.т.Алексеевское № 379

**«Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының 2025-2030 елларга халыкның сәламәтлеген яхшырту һәм үлем очракларын киметү» муниципаль программасын раслау турында**

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты халык сәламәтлеген саклау һәм ныгыту өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыру максатларында

**карар бирә**:

1. «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының 2025-2030 елларга халыкның сәламәтлеген яхшырту һәм үлем очракларын киметү» муниципаль программасын расларга.

2. Алексеевск муниципаль районының финанс-бюджет палатасына чараларны финанслау өчен акча бүлеп бирүне күздә тотарга.

3. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының 2022-2024 елларга халыкның сәламәтлеген яхшырту һәм үлем очракларын киметү» максатчан программасын раслау турында 07.06.2022 ел, № 225 карары үз көчен югалткан дип санарга.

4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында һәм ТР Хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Е.А.Хәмзинага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **О.Н. Леденцов**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
08.09.2025 № 379
карарына кушымта

**«Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының 2025-2030 елларга халыкның сәламәтлеген яхшырту һәм үлем очракларын киметү»**
**МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАСЫ**

**Программаның Паспорты**

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының 2025-2030 елларга халыкның сәламәтлеген яхшырту һәм үлем очракларын киметү» Алексеевск муниципаль районының Муниципаль программасы |
| Программаның заказчысы | Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаның төп эшләүчеләре | «Алексеевск үзәк район хастаханәсе» ДАССО, Башкарма комитетның ЗАГС бүлеге, спорт бүлеге, яшьләр эшләре секторы, Яңа Чишмә, Спас, Чистай, Алексеевск районнарында Роспотребнадзор Идарәсенең территориаль бүлеге |
| Программаның төп максатлары һәм бурычлары | Тормыш дәрәҗәсен тотрыклы күтәрү, сәламәтлек саклауны үстерү, халыкны деалкоголизацияләү һәм денаркотизацияләү, хезмәтне саклау һәм социаль ярдәм чараларын камилләштерү буенча эзлекле сәясәт уздыру чаралары ярдәмендә халыкның үлемен киметү.<br>Халыкта кече яшьтән башлап, кирәкле заманча шартлар тудыру һәм сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау юлы белән физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә ихтыяҗ тудыру.<br>Туучылар санын арттыруга ярдәм итү. Гаиләне, иң мөһим социаль институт буларак, саклап калу һәм үстерү. |

| | |
|---|---|
| Программаны тормышка ашыру вакыты | 2025-2030 еллар |
| Программаны үтәүчеләр | «Алексеевск үзәк район хастаханәсе» ДАССУ, Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының ЗАГС бүлеге, Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлеге, «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ, спорт бүлеге, яшьләр эшләре секторы, ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Алексеевск муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге, Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге, шәһәр һәм авыл җирлекләре башкарма комитетлары җитәкчеләре, мөхтәсиб, православие |
| Финанслауның күләме һәм чыгананаклары | Җирле бюджет акчалары<br>Барлыгы: 3 600,0 мең сум.<br>2025 елда-600,0 мең сум.<br>2026 елда-600,0 мең сум.<br>2027 елда-600,0 мең сум.<br>2028 елда-600,0 мең сум.<br>2029 елда-600,0 мең сум.<br>2030 елда-600,0 мең сум.<br>Чараларны үтәүгә программада каралган акча күләме Алексеевск муниципаль районы бюджетының керем өлешен үтәүгә бәйле рәвештә салым һәм салым булмаган керемнәр исәбеннән дә, Алексеевск муниципаль районы бюджетына керә торган бюджетара трансфертлар исәбеннән дә үзгәрергә мөмкин |
| Программаны тормышка ашыруның көтелгән соңгы нәтиҗәләре | 1. 2030 елга үлүчеләр санының 20% ка кимүе.<br>2. Хезмәткә сәләтле яшьтәге халыкның |

| | |
|---|---|
| | үлү очракларының 2030 елга 20% ка кимүе.<br>3. Халыкның гомер озынлыгын арттыру, тормыш сыйфатын, халыкның сәламәтлеген яхшырту.<br>4. Медицина проблемасы-кадрлар җитмәү, бигрәк тә авылда. Аны хәл итү өчен «Земский доктор»федераль программасы эшли башлады. |
| Программаның үтәлешен контрольдә тоту | Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты |

## 1.Программа тарафыннан, хәл итүгә юнәлгән проблеманың характеристикасы.

Россия Федерациясе Президентының «2025 елга кадәр чорга Россия Федерациясенең демографик сәясәте концепциясен раслау турында» 2007 елның 9 октябрендәге 1351 номерлы Указы, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Сәламәтлек саклауны үстерү» «Россия Федерациясенең дәүләт программасын раслау турында» 2017 елның 26 декабрендәге 1640 номерлы карары нигезендә халыкның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту дәүләт сәясәтен формалаштыруның өстенлекле бурычларның берсе булып тора. «Россия Федерациясендә гражданнар сәламәтлеген саклау нигезләре турында» 2011 елның 21 ноябрендәге 323-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә сәламәтлек саклау системасында принципиаль яңа юнәлеш - авыруны дәвалауга юнәлдерелгән системадан гражданнарның сәламәтлеген саклау системасына күчү-сәламәт яшәү рәвеше приоритетына юнәлтелгән һәм авыруларны профилактикалауга юнәлтелгән.

Кадрлар җитмәү белән проблеманы хәл итү өчен, медицина өлкәсендәге яшь профессионалларга, авыл җирендә белгечлеге һәм тотрыклы түләүле даими эш урыны алуга федераль ярдәм йөзеннән «Земский доктор» программасы кабул ителде, шулай ук дәүләт тарафыннан кайбер ташламалы өстенлекләр һәм матди ярдәм каралган («Россия Федерациясендә мәҗбүри медицина иминияте турында»2010 елның 29 ноябрендәге 326-ФЗ номерлы Федераль закон (2016 елның 28 декабрендәге 472-ФЗ номерлы редакциядә).

Проблеманың актуальлеге шунда ки, аерым уңай моментларга карамастан, сәламәтлек күрсәткечләре түбән дәрәҗәдә саклана. Дәүләтнең икътисадый һәм социаль үсешендә катлаулы шартлар күпләп авыручылар һәм үлүчеләр санында, туучылар санының түбән дәрәҗәләрендә, аналарның һәм балаларның сәламәтлегендә күзәтелә. Моннан тыш, хәзерге вакытта халык сәламәтлегенең социаль яктан бәйле һәм һөнәри яктан бәйле дефектлары үсә.

Халыкның сәламәтлеген ныгыту һәм үлемнәрне киметү программасы бүген район муниципаль хакимияте органнары, социаль тәэмин итү һәм сәламәтлек саклау өлкәләре белән кичекмәстән хәл итү өчен беренчеләр рәтендә тора. Халык сәламәтлеген, медицина хезмәте күрсәтү дәрәҗәсен, демографик вәзгыятьне, хезмәтне саклау, физик культура һәм спорт үсешен характерлаучы кайбер аспектларга мөрәҗәгать итсәк, проблема тагын да аңлаешлырак була бара.

## 1.1 Демографик ситуациягә анализ

Үлүчеләр саны югары булу район халкы саны кимүнең төп сәбәбе булып тора. 2014 елдан районда үлүчеләр саны туучылар санынnan артып китте һәм тотрыклы характерга ия.

**2014-2024 елларда Алексеевск районы буенча туучылар саны күрсәткече ТР белән чагыштырганда (абс.саннар һәм 1000 кешегә )**

| Еллар | Туучылар саны | Район буенча туучылар | ТР буенча туучылар |
|---|---|---|---|
| 2014 | 387 | 14,8 | 14,7 |
| 2015 | 346 | 13,3 | 14,7 |
| 2016 | 282 | 10,9 | 14,3 |
| 2017 | 269 | 10,5 | 12,4 |
| 2018 | 233 | 9,2 | 11,9 |
| 2019 | 266 | 10,6 | 10,9 |
| 2020 | 219 | 8,8 | 11,0 |
| 2021 | 240 | 9,7 | 10,5 |
| 2022 | 215 | 8,8 | 10,1 |
| 2023 | 203 | 8,2 | 9,1 |
| 2024 | 184 | 7,5 | 8,8 |

Соңгы ун ел эчендә туучылар саны теге яки бу якка аз гына тирбәлә, туучылар саны кимү тенденциясе күзәтелә.

**2014-2024 елларда Татарстан Республикасы белән чагыштырганда Алексеевск районы буенча үлемнәр күрсәткече (абсолют саннар һәм 1000 кешегә)**

| Еллар | Үлүчеләр саны | Район буенча үлүчеләр | ТР буенча үлүчеләр |
|---|---|---|---|
| 2014 | 428 | 16,4 | 12,2 |
| 2015 | 382 | 14,7 | 12,0 |
| 2016 | 368 | 14,2 | 11,6 |
| 2017 | 343 | 13,4 | 11,3 |
| 2018 | 382 | 15,1 | 11,4 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 2019 | 379 | 15,1 | 11,0 |
| 2020 | 427 | 17,2 | 11,0 |
| 2021 | 419 | 17,0 | 15,5 |
| 2022 | 342 | 14,0 | 11,5 |
| 2023 | 327 | 13,3 | 10,7 |
| 2024 | 358 | 14,6 | 11,3 |

Соңгы ун ел дәвамында үлем күрсәткечләре теге яки бу якка аз гына тирбәлә, 2024 елда 2014 елга карата үлүчеләр саны 11,0% ка кимү тенденциясе күзәтелә.

**Алексеевск районы буенча 2014-2024 елларда халыкның табигый хәрәкәте коэффициентлары (1000 кешегә)**

| Еллар | Туу | Үлү | Табигый үсеш (кимү) |
|---|---|---|---|
| 2014 | 14,8 | 16,4 | - 1,6 |
| 2015 | 13,3 | 14,7 | - 1,4 |
| 2016 | 10,9 | 14,2 | - 3,3 |
| 2017 | 10,5 | 13,4 | - 2,9 |
| 2018 | 9,2 | 15,1 | - 5,9 |
| 2019 | 10,6 | 15,1 | -4,5 |
| 2020 | 8,8 | 17,2 | -8,4 |
| 2021 | 9,7 | 17,0 | -7,3 |
| 2022 | 8,8 | 14,0 | -5,2 |
| 2023 | 8,2 | 13,3 | -5,1 |
| 2024 | 7,5 | 14,6 | -7,1 |

Соңгы ун ел дәвамында халыкның табигый хәрәкәт күрсәткече теге яки бу якка аз гына тирбәлә.

Тискәре табигый үсеш 2014 елдан бирле теркәлгән. Әлеге программаның максаты-районда табигый кимүне киметү.

Үлем структурасында берничә ел дәвамында кан әйләнеше системасы авырулары өстенлек итә. 2024 елда үлем структурасында беренче урында кан әйләнеше системасы авыруы (31,5%). Икенче урында – тышкы сәбәпләр (16,9%), өченчедә (13,7%) - яңа шешләр.

2024 елда хезмәт яшендәге гомуми үлүчеләр саны 21,0% ка арткан, җәрәхәтләрдән, агуланулардан һәм тышкы сәбәпләр нәтиҗәләреннән үлүчеләр саны 35% ка арткан, әмма юл-транспорт һәлакәтләреннән 1,4 тапкырга кимегән, хезмәт яшендәге сулыш органнары авыруларыннан һәм ашкайнату органнары авыруларыннан үлүчеләр саны шулай ук 2023 ел дәрәҗәсендә.

**Аерым демографик күрсәткечләр (барлык халык)**

| **Үлем сәбәбе** | **Территория** | **2020 ел** | **2021 ел** | **2022 ел** | **2023 ел** | **2024 ел** |
|---|---|---|---|---|---|---|

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Кан әйләнеше системасы авырулары | Алексеевск районы | 584,7 | 483,4 | 498,8 | 397,1 | 460,5 |
| | Татарстан | 657,7 | 565,8 | 530,7 | 498,0 | 453,8 |
| Сулыш юлы органы авырулары | Алексеевск районы | 72,1 | 85,3 | 73,6 | 174,3 | 77,4 |
| | Татарстан | 98,0 | 81,0 | 51,1 | 63,4 | 71,4 |
| Аш кайнату органы авырулары | Алексеевск районы | 40,0 | 56,9 | 61,3 | 72,9 | 85,6 |
| | Татарстан | 67,7 | 69,1 | 64,2 | 68,8 | 87,6 |
| Яңа барлыкка килгән шешләр | Алексеевск районы | 236,3 | 174,7 | 171,7 | 162,1 | 191,5 |
| | Татарстан | 186,8 | 175,4 | 172,8 | 175,7 | 179,5 |
| Тышкы сәбәпләр | Алексеевск районы | 100,5 | 73,1 | 77,7 | 149,9 | 269,0 |
| | Татарстан | 78,3 | 79,0 | 80,6 | 85,9 | 132,1 |
| Сабыйлар үлеме | Алексеевск районы | 5,2 | 12,5 | 4,7 | 4,7 | 0 |
| | Татарстан | 4,1 | 4,0 | 3,3 | 3,1 | 2,6 |
| Аналар үлеме | Алексеевск районы | **0** | 0 | **0** | 0 | **0** |
| | Татарстан | 2,4 | 14,6 | 8,2 | 8,2 | 0 |

2023 елның башлангыч стадияләрендә ачыкланган яман шешләр өлеше-46%

Бер еллык үлем күрсәткече 2022 елда – 30,3 %, 2023 елда – 22,9%, 2024 елда-22,4% (2022 елга карата 26% ка кимү).

**Аерым демографик күрсәткечләр**
**(эшкә яраклы халык)**

| **Үлем сәбәбе** | **Территория** | **2020 год** | **2021 год** | **2022 год** | **2023 год** | **2024 год** |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Эшкә яраклы халыкның үлеме | Алексеевск районы | 336,4 | 523,7 | 573,9 | 649,4 | 837,1 |
| | Татарстан | 461,6 | 503,7 | 451,8 | 457,3 | 557,9 |
| Кан әйләнеше системасы авырулары | Алексеевск районы | 246,2 | 179,4 | 226,7 | 209,3 | 194,8 |
| | Татарстан | 160,4 | 151,4 | 149,9 | 144,7 | 132,1 |
| Сулыш юлы органы авырулары | Алексеевск районы | 61,6 | 35,9 | 28,3 | 28,9 | 14,4 |
| | Татарстан | 24,6 | 23,3 | 17,2 | 17,3 | 24,7 |
| Аш кайнату органы авырулары | Алексеевск районы | 38,5 | 43,0 | 63,8 | 57,7 | 79,4 |
| | Татарстан | 52,7 | 54,2 | 50,9 | 54,4 | 73,2 |
| Яңа барлыкка килгән шешләр | Алексеевск районы | 61,6 | 43,0 | 70,9 | 72,2 | 101,0 |
| | Татарстан | 64,6 | 63,9 | 65,6 | 64,1 | 73,4 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Тышкы сәбәпләр | Алексеевск районы | 90,9 | 107,6 | 99,2 | 245,3 | 389,7 |
| | Татарстан | 92,7 | 93,4 | 98,4 | 109,3 | 181,7 |

Күрсәтелгән таблицадан күренгәнчә, 2020-2024 еллар аралыгында хезмәткә сәләтле яшьтә үлем структурасында алдынгы урынны тышкы сәбәпләр ала башлаган, икенче урында кан әйләнеше системасы авырулары, өченчедә - шешләр.

Хезмәткә сәләтле яшьтә халыкның үлүе бик тискәре. Үлгәннәр арасында әле яңа гына тормышка аяк баскан яшьләр күп.

Туучы һәм үлүчеләр саны демографиянең иң мөһим күрсәткечләрен генә түгел, тулаем алганда социаль-икътисадый үсешнең төп интеграль характеристикаларын да тәшкил итә. Халыкның табигый артуына, үлүчеләр саны кимүгә, тулаем халыкның сәламәтлегенә аеруча нык тәэсир итә торган кайбер аспектларны карап чыгыйк.

### 1.2. Халыкны алкогольләштерү.

Бигрәк тә яшь һәм өлкән яшьтә, үлем-китем очраклары артуга алкоголь, шул исәптән суррогат, наркотиклар һәм башка психотроп матдәләр куллану тискәре йогынты ясый.

**2020-2024 елларда табиб-наркологта исәптә торучы диспансер авырулар.**

| | 2020 ел | 2021ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел |
|---|---|---|---|---|---|
| Эчкечелек, аларның стадияләре белән | 149 | 164 | 162 | 188 | 199 |
| башлангыч(1) | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 |
| урта (2) | 148 | 163 | 161 | 187 | 198 |
| Наркомания | 9 | 10 | 1 | 2 | 13 |
| Токсикомания | - | - | - | - | - |

Таблицадан күренгәнчә, нарколог табибында исәптә торучылар саны арта бара. Әйтик, 2024 елда 2020 ел белән чагыштырганда 1,4 тапкырга арткан. Алкоголизмнан интегүчеләр саны шулай ук үсеш тенденциясенә ия.

**Бала табу яшендәге хатын-кызлар арасында социаль-әһәмиятле авырулар: психоневрология диспансерында, наркология диспансерында наркомания һәм эчкечелек аркасында исәптә торучылар саны. ВИЧ, СПИД инфекцияләре белән авыручылар, еллар буенча динамика:**

| Еллар | Наркологик | Психоневрологик | Ачыкланган ВИЧ, |
|---|---|---|---|

| | диспансерда барлык исәптә торучылар | диспансерда барлык исәптә торучылар | СПИД авырулары |
|---|---|---|---|
| 2014 | 13 | 42 | 1 |
| 2015 | 14 | 35 | 4 |
| 2016 | 19 | 31 | 2 |
| 2017 | 42 | 32 | 2 |
| 2018 | 51 | 41 | 2 |
| 2019 | 56 | 41 | 1 |
| 2020 | 64 | 40 | 2 |
| 2021 | 68 | 43 | 1 |
| 2022 | 66 | 42 | 1 |
| 2023 | 68 | 44 | 2 |
| 2024 | 68 | 45 | 1 |

**2014-2024 елларда Алексеевск районы буенча алкоголь белән агулану динамикасы**

| Еллар | Агуланулар саны | Шул исәптә үл-р | Шул исәптә хатын-кызлар |
|---|---|---|---|
| 2014 | 6 | 5 | 3 |
| 2015 | 4 | 4 | 0 |
| 2016 | 3 | 3 | 1 |
| 2017 | 2 | 2 | 2 |
| 2018 | 3 | 2 | 1 |
| 2019 | 4 | 3 | 1 |
| 2020 | 1 | - | 1 |
| 2021 | 1 | 1 | - |
| 2022 | 2 | 1 | - |
| 2023 | 2 | 2 | - |
| 2024 | 2 | 2 | - |

Анализ күрсәткәнчә, 2014-2024 елларда наркология диспансерында исәптә торучылар саны арту тенденциясе күзәтелә, ә психоневрология диспансерында торучылар саны бер дәрәҗәдә диярлек. Ел саен ВИЧ-инфекцияле якынча 1-2 кеше ачыклана.

## 1.3. Никахлар һәм аерылышулар

Тормыш дәрәҗәсенең иминлегенә, сәламәтлегенең торышына никах һәм аерылышулар тенденциясе турыдан-туры йогынты ясый.

**Яшь һәм җенес буенча никахлар саны**

| | ир-атлар | | | | | хатын-кызлар | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | **2020** | **2021** | **2022** | **2023** | **2024** | **2020** | **2021** | **2022** | **2023** | **2024** |
| 18 гә кад. | 0 | 0 | 0 | 1 | 0 | 3 | 3 | 1 | 2 | 2 |
| 18-24 | 33 | 45 | 47 | 27 | 38 | 38 | 60 | 58 | 38 | 36 |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 25-34 | 32 | 35 | 50 | 33 | 41 | 28 | 23 | 43 | 26 | 28 |
| 35-44 | 11 | 12 | 26 | 24 | 13 | 10 | 7 | 21 | 18 | 19 |
| 45-54 | 4 | 9 | 9 | 10 | 9 | 3 | 9 | 11 | 7 | 13 |
| 55 һәм өл. | 6 | 7 | 5 | 10 | 7 | 4 | 6 | 3 | 2 | 7 |
| **Яшь һәм женес буенча аерылышучылар саны** | | | | | | | | | | |
| | ир-атлар | | | | | хатын-кызлар | | | | |
| | **2020** | **2021** | **2022** | **2023** | **2024** | **2020** | **2021** | **2022** | **2023** | **2024** |
| 18 гә кад. | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| 18-24 | 1 | 6 | 1 | 5 | 9 | 1 | 7 | 8 | 8 | 15 |
| 25-34 | 10 | 23 | 18 | 12 | 24 | 19 | 30 | 26 | 28 | 39 |
| 35-44 | 12 | 13 | 16 | 16 | 24 | 18 | 34 | 24 | 18 | 21 |
| 45-54 | 4 | 7 | 5 | 2 | 5 | 7 | 9 | 7 | 2 | 5 |
| 55 һәм өл. | 5 | 2 | 3 | 2 | 2 | 2 | 7 | 2 | 1 | 1 |

Җәмгыятьтә социаль иминлек дәрәҗәсе турында, гаилә институты эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге яки нәтиҗәсезлеге турында никахлар һәм аерылышулар нисбәте сигнал бирә.

Елына уртача 79 бала бер ата-ана белән кала. Бу үзләренең күпчелегендә ата-аналары кылган аерылышудан психик җәрәхәтләр алган балалар, еш кына тулы канлы туклану алу мөмкинлеге булмый.

Соңгы елларда гражданлык никахлары саны артты, соңыннан барысы да рәсми рәвештә теркәлми.

## 1.4. Гомер озынлыгы.

Халык сәламәтлеге һәм үлү дәрәҗәсенең чагылышы туу вакытындагы көтелгән гомер озынлыгы күрсәткече булып тора. Үлүчеләр санының югары дәрәҗәсе көтелгән гомер озынлыгының түбән күрсәткечләрен билгели.

**Алексеевск районы буенча көтелә торган гомер (ел) озынлыгы.**

| | | **2026** | **2027** | **2028** | **2029** | **2030** |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Район | ир-атлар | 65,3 | 66,4 | 67,5 | | |
| | хатын-кызлар | 78,4 | 79,5 | 80,6 | | |
| ТР | ир-атлар | 69,7 | 72,6 | 71,2 | 69,78 | 69,78 |
| | хатын-кызлар | 79,9 | 72,6 | 71,2 | 79,82 | 80,52 |

Хатын-кызларның уртача гомер озынлыгы 80,6 яшь, ир-атларның 67,5 яшь, аерма 13,1 яшь тәшкил итәчәк. Игътибар итегез, республика буенча бу күрсәткеч ел саен югарырак күрсәткечләргә ия.

## 1.5. Үлем проблемаларының характеристикасы һәм аларны

**хәл итү буенча төп юнәлешләр**

**1.5.1. Кан әйләнеше системасы авыруларыннан.**

Ел саен дөньяда кан әйләнеше системасы авыруларыннан дистәләгән миллион кеше үлә, шул исәптән йөрәкнең ишемик авыруыннан — 87 миллионнан артык.

Россия Федерациясендә эшкә яраклы халык арасында йогышлы булмаган авырулардан вакытсыз үлем саны структурасында КӘСА өлешенә ир-атларда- 36,6%, хатын-кызларда-40,5% туры килә.

КӘСА үсешенә һәм таралуына йогынты ясаучы төп фактор булып артериаль гипертония тора, ул россиялеләр арасында 39,0% ир-атта һәм 41,0% хатын-кызларда теркәлгән. Тулаем Россия Федерациясе буенча 41 миллионнан артык артериаль гипертония белән авыручы теркәлгән. 40 яшькә кадәрге артериаль гипертония белән авыручыларның алда торган гомернең уртача озынлыгы 6 елга кыскара.

Татарстан Республикасында, тулаем Россия буенча кебек үк, өлкән халык арасында кан әйләнеше системасы авырулары белән авыручылар санының артуы күзәтелә.

Хәзерге вакытта республикада артериаль гипертониядән интегүче 300 меңгә якын кеше, ягъни һәр унынчы кеше диярлек теркәлгән.

Татарстан Республикасы буенча үлем структурасында 2024 елда (алдагы еллардагы кебек үк) кан әйләнеше системасы авырулары өстенлек итә - 36,8% (2023 елда – 41,8%); күрсәткеч 100 мең кешегә 453,0 тәшкил итте, бу 2023 ел күрсәткеченнән 9,0% ка түбәнрәк.

Татарстан Республикасы буенча гипертония авыруыннан үлүчеләр саны 8,2% ка кимегән һәм 100 мең кешегә 41,4% тәшкил иткән (2024 елда - 45,0), гипертония авыруыннан үлүчеләр саны 2023 ел белән чагыштырганда 138 кешегә кимрәк.

Миокард инфарктыннан үлүчеләр саны 4,8% ка арткан, ул 100 мең кешегә 47,9 тәшкил иткән.

Алексеевск муниципаль районында 2024 елда КАСӘ ның беренчел авырулары 2023 ел белән чагыштырганда 15,9% ка арткан (2023 елда – 100 мең кешегә 397,1, 2024 елда-460,5).

| | 2023 ел | 2024 ел |
|---|---|---|
| Барлык теркәлгән КӘСА | 9511 | 9871 |
| беренчел | 1750 | 1789 |
| Проф.карау вакыт. ачык. | 52 | 63 |
| Диспансеризация вак. | 6 | 16 |
| АГ | 4030 | 4208 |
| ИБС | 1172 | 1246 |
| ХИБС | 677 | 739 |
| ИМ | 26 | 29 |
| тромболизис | 10 | 13 |

| | | |
|---|---|---|
| ОНМК | 83 | 71 |
| ЦВБ | 981 | 977 |

2024 елда КӘСА дан 108 кеше, шул исәптән хезмәткә яраклы яшьтә – 27 кеше үлгән. 2023 елда-89 кеше, шул исәптән хезмәткә яраклы - 25 кеше.

Төп яшьләр -60 яшь һәм аннан өлкәнрәкләр – 2024 елда 70,8% һәм 2023 елда 73,0%.

2024 елда инфаркттан үлүчеләр – 3 кеше, инсульттан – 15 кеше.

2023 елда инфаркттан үлүчеләр-2 кеше, инсульттан-8 кеше.

Пациентларның Чистай шәһ. ОНМК белән җибәрү зур роль уйный-60 кеше, һәм Казан шәһәренә МИ белән - 27 кеше. Тромболизисны үткәрү, МРТ, РКТ, АКШ һ.б. квоталарны куллану, РКХнең консультатив сырхауханәсенә кабул итүгә язылу, халык арасында СПР үткәрү.

Хәзерге вакытта районда артериаль гипертониядән интегүче 527 кеше теркәлгән.

Бүгенге көндә халыкка өстәмә профилактик тикшерүләр үткәрү зарур. Мондый авыруларны ачыклауда ФАП фельдшерларына һәм гомуми практика табибларына зур роль бирелә.

### 1.5.2. Яман шешләрдән үлүчеләр проблемасына характеристика.

Татарстан Республикасы буенча 2021 елда яман шештән үлүчеләр саны 2,2% ка арткан,100 мең кешегә 179,4 очрак (2023 елда-175,7). Яман шеш авыруларыннан үлүчеләр санының гомуми структурасында 11,3% тәшкил итә.

2024 елда үлүчеләрнең абсолют саны 6813 кеше тәшкил итте. Үлем очракларының төп артуы ир-ат женси органнары (27,6%), сулыш органнары (9,9%), ашкайнату органнары (8,7%) хисабына булган.

Яшь категорияләре буенча төп үсеш пенсия яшендәге кешеләр арасында - 656 кешегә, ягъни 12,3% ка арткан.

Эшкә яраклы халыкның үлем саны структурасында яман шеш өченче урында тора (15,3%) - тиешле яшьтәге 100 мең кешегә 74,1 очрак. Алексеевск муниципаль районында (101,0) халыкның яман шеш авыруыннан үлүчеләр санының шактый югары күрсәткечләре билгеләп үтелде.

2024 елда беренчел яман чирләр саны, 2023 ел белән чагыштырганда, 5,3% ка (2024 елда - 1000 кешегә 8,0, 2023 елда-7,6), таралыш 6% ка арткан.

Яман шешләрдән үлүчеләр-47 кеше, шул исәптән эшкә яраклы кешеләр - 14 кеше, 2023 елда – 39 кеше, эшкә яраклы кешеләр – 10 кеше. Кимү-3,9%.

| Шешләр | 2023 ел | 2024 ел |
|---|---|---|
| Бар-к терк-н авыр-р . | 735 | 775 |
| беренчел | 103 | 105 |
| Проф.карау вак. ачык. | 4 | 6 |
| Диспансеризация вак. | 16 | 14 |
| Яман шеш авыр.ел .баш. | 628 | 663 |

Авырулар структурасында шешләрнең түбәндәге локализацияләре алда бара: сөт бизе, меланомалы тире, юан эчәклек, үпкә, мәни бизе, ашказаны. Күрсәтелгән локализацияләр халыкның онкология авырулары структурасында 62,5% тәшкил итә. 2023 ел белән чагыштырганда, сөт бизенең яман шеше, тире меланомасы яман шешен узып, 2-дән 1-нче позициягә күчте. Ир-атларда 2024 елда мәни бизе яман шешләре әйдәп баручы локализациясе булып тора-18,8%. Хатын-кызлар арасында яман шешне локализацияләү арасында сөт бизе беренче урында (22,4%).

ТРда яшәүче һәр 43 нче кеше яман шеш диагнозы белән исәптә тора. 5 һәм аннан да күбрәк ел исәптә торучы авырулар 2024 елда 55,3% тәшкил иткән (2023 елда - 54,8%, Россия Федерациясендә - 52,4%).

Бер еллык үлем очраклары 0,6% ка кимегән, ул 26,5% тәшкил итә. Алексеевск районында бер еллык үлем күрсәткече 22,4% тәшкил итә.

Яман шешләрнең азган булуының югары күрсәткечләре иртә диагностикага һәм профилактикага, бигрәк тә сөт һәм мәни бизенең яман шеше, аналык муентыгы кебек визуаль формаларга карата чараларны активлаштыру кирәклеге турында сөйли.

Хатын-кызлар арасында яман шештән үлем саны структурасында сөт бизенең яман шеше беренче урында тора. Шуңа бәйле рәвештә, авыруны иртә стадияләрдә дөрес ачыкларга мөмкинлек бирүче маммографик скрининг аерым әһәмияткә ия. Скрининг уңышын тәэмин итүнең мәҗбүри шарты булып, аларга карап тикшерелергә тиешле халыкның кимендә 70% ын колачлау тора.

Онкология авыруларының якынча өчтән бер өлеше аналык муентыгы яман шешенә туры килә. Шуңа бәйле рәвештә фон авыруларын, яман шешкә кадәрге халәтләрне һәм клиник стадиядиягә кадәрге яман шешне ачыкларга мөмкинлек бирүче скрининг мөһим роль уйный, аларны үз вакытында дәвалау, яман шеш барлыкка килүне кисәтергә ярдәм итә. Аналык муентыгы яман шеше скринингына хатын-кызлар 18 яшьтән өч елга 1 тапкыр периодик рәвештә килергә тиеш, процедура хатын-кызларның 80% тан да ким булмаган өлешен колачларга тиеш.

Районда мәни бизенең яман шеше ир-атлар арасында онкологик авырулар структурасында икенче урында тора. Бүген мәни бизенең яман шешен иртә диагностикалауга юнәлтелгән даими скрининг тикшеренүләре уздырганда иртә стадияләрне ачыклау саны артуы исбатланды, яман шешнең метастатик формалары табылмый диярлек. Даими рәвештә тикшерү узучы ир-атларда простата яман шешеннән үлү ихтималы 3 тапкыр кими.

Районда үлүчеләр саны структурасында яңа барлыкка килүләр өлешенә 13,7% туры килә.

### 1.5.3. Тышкы сәбәпләр һәм имгәнүләрдән үлемнәр проблемасына характеристика.

Травматизм һәм аның нәтиҗәләре иң мөһим медик-социаль проблемаларның берсе булып тора.

Татарстан Республикасы буенча тышкы сәбәпләрдән үлүчеләр саны буенча өченче урында тора (өлеш-8,1%), 2024 елда, 2023 ел белән чагыштырганда, күрсәткеч 9,8% ка артты; 100 мең кешегә 132 очрак тәшкил итте. Алексеевск муниципаль районында тышкы сәбәпләрдән үлүчеләр саны күрсәткече 52,6% ка яисә 2023 ел белән чагыштырганда 1,5 тапкыр арткан (2024 елда – 58 кеше, 2023 елда-38 кеше үлгән).

Алексеевск районында травмалар, агуланулар һәм кайбер тышкы йогынтылар эшкә яраклы халыкның үлем-китем структурасында 1 нче урынны алып тора. Эшкә яраклы кешеләрнең инвалидлыкка беренчел чыгу сәбәпләре структурасында алар 3 нче позицияне били.

Ашыгыч һәм кичектергесез медицина ярдәме хезмәте-сәламәтлек саклау системасында иң мөһим бүлекчәләрнең берсе, аның социаль әһәмияте бәхетсезлек очракларының, кинәт авыруларның һәм гадәттән тыш хәлләр санының артуына бәйле рәвештә ел саен арта.

2024 елда барлыгы 7438 тапкыр авырулар янына бару булган, шуларның 6573 се район үзәгендә, 865 е район үзәгеннән читтә. Ашыгыч һәм кичектергесез медицина ярдәме күрсәтүнең сыйфаты мәсьәләсе турыдан-туры медицина кадрларын әзерләү дәрәҗәсенә бәйле. Авырулар янына чыгу вакытында урта звено белгечләре ярдәм итә. Беркетелгән муниципальара үзәкләргә маршрутлаштыру зур әһәмияткә ия.

Безнең район халкының яртысыннан артыгы авыл җирендә яши, шуңа күрә медицина ярдәме күрсәтүдә фельдшер-акушерлык пунктларына зур роль бирелә. Соңгы 10 елда 21 модульле ФАП төзелде һәм файдалануга тапшырылды. Районның фельдшер-акушерлык пунктлары медицина персоналы белән комплектланган.

### 1.5.6. Медицина кадрлары белән тәэмин ителеш.

Әлеге программаның юнәлеше,чираттагы эше –ул кадрлар. Дәвалау учреждениеләренең медицина кадрлары белән җитәрлек дәрәҗәдә тәэмин ителмәве район халкының медицина ярдәмен тәэмин итүгә турыдан-туры йогынты ясый, аны бүген тулы кыйммәтле дип әйтеп булмый. Районның ДПУлары тар белгечләргә (эндокринолог, невролог һ.б.), гомуми практика табибларына, терапевтларга бик мохтаҗ.

Хастаханәдә 320 хезмәткәр эшли, шулардан табиблар - 45, урта медицина персоналы - 176, кече медицина персоналы - 13 һәм башкалар 73.

2024 елда Алексеевск үзәк район хастаханәсе штатын табиб анестезиолог, отоларинголог, эпидемиолог, 15 урта медицина хезмәткәре тулыландырды.

Табиблар белән тәэмин ителеш 76,2% тәшкил итә, табиб кадрлары белән тәэмин ителеш 18,2% тәшкил итә.

2024-2030 елларга кадрлар белән тәэмин итү буенча «Юл картасы» эшләнгән.

«Алексеевск үзәк район хастаханәсе» ДАССОга яшь табибларны җәлеп итү максатында торак белән тәэмин итү мөмкинлеге эзләнә.

Ел саен Алексеевск муниципаль районы башлыгы грантына конкурс үткәрелә: «Иң яхшы табиб», «Иң яхшы урта медицина хезмәткәре», «Иң яхшы ФАП медицина хезмәткәре».

Хәзерге вакытта «Алексеевск үзәк район хастаханәсе» ДАССОда вакантлы вазыйфалар кала: гомуми практика табибы, анестезиолог-реаниматолог, кардиолог, терапевт, ФАП фельдшеры.

### 1.5.7. Халыкның репродуктив сәламәтлеге торышы.

Йөкле хатын-кызларны Чистай һәм Казан шәһәрләрендә перинаталь үзәкләргә озаталар. Йөклелек патологиясенең төп сәбәбе-анемия (барлык йөкле хатын-кызларның 38% ы). Моңа йөкле кешеләрнең сәламәтлеген саклау өчен кирәкле тимерле препаратлар, поливитамин һәм йодлы препаратлар булмау да ярдәм итә. Моннан тыш, булачак әниләрнең сәламәт яшәү рәвешен алып баруның түбән дәрәҗәдә булуын, тиешле дәрәҗәдә оештырылмаган санитар-агарту эшен дә билгеләп үтәргә кирәк.

Йөкле хатын-кызларны хатын-кызлар консультациясенә исәпкә куюның үз вакытында булуы зур әһәмияткә ия. Йөкле хатын-кыз табибта ничек иртәрәк күзәтелә башласа, авыру бала туу куркынычы да шулай азрак була.

«Авыру ата-аналарның сәламәт балалары булмый» дигән танылган гыйбарә бар. Репродуктив сәламәтлекнең начараюы балаларның сәламәтлегенә йогынты ясамыйча кала алмый. 18 яшькә кадәрге балаларның арасында авыручылар саны югары булып кала бирә.

Соңгы биш елда сабыйлар арасында үлүчеләр саны да шактый югары, гәрчә 2024 елда сабыйлар арасында үлүчеләр саны теркәлмәгән булса да, 2023-2022 елда 1 әр очрак теркәлгән.

**Йөклелекне ясалма рәвештә өздерү**

| | 2020 | 2021 | 2022 | 2023 | 2024 |
|---|---|---|---|---|---|
| Аборт саны | 88 | 67 | 52 | 41 | 0 |

Абортлар хатын-кызларның репродуктив потенциалына һәм репродуктив сәламәтлек дәрәҗәсенә сизелерлек йогынты ясый. Йөклелекне ясалма өзү, бигрәк тә беренче йөклеләрдә, икенчел бала тапмау куркынычы яный. Беренче йөклеләрнең абортлар өлеше соңгы елларда РФ буенча 10 – 11% тәшкил итә, 2023 елда районда - 1,3%. Бу юнәлештә йөкле хатыннар белән һәм беренче чиратта медицина хезмәткәрләре тарафыннан санитар-агарту эшен көчәйтергә кирәк.

### 1.5.8. Экологик халәт.

2025 елның 1 гыйнварына район территориясендә 52 эчәргә яраклы суүткәргеч исәпләнә («Алексеевск Водоканалы» ААҖ 46 суүткәргечкә хезмәт күрсәтә).

Алексеевск ш.т. б. халкының 100% ы һәм район авыл кешеләренең 99,8% ы үзәкләштерелгән су белән тәэмин ителгән.

Алексеевск районының 43 кешесе кое суыннан файдалана. Алар-Гоголиха, Баганалы урман хуҗалыгы поселогы һәм Березовка авылы халкы.

Микробиологик күрсәткечләр буенча гигиена нормативларына туры килми торган эчәргә яраклы су пробалары өлеше 2022 елда– 36,4%, 2023 елда – 4,7%, 2024 елда - 4,1% тәшкил итте. Химия күрсәткечләре буенча бүлү челтәрендәге суның сыйфаты соңгы еллар дәвамында тотрыклы булып тора, гигиена нормативларына туры килми торган пробалар проценты 25% тәшкил итә.

Микробиологик һәм санитар-химик күрсәткечләр буенча су туры килмәүнең төп проблемасы:

- табигый характердагы факторлар (гомуми катгыйлыкның югары күрсәткечләре, тимернең югары булуы);
- гамәлдәге суүткәргеч челтәрләренең һәм корылмаларының түбән санитар-техник торышы;
- җитештерү контролен тулысынча үтәмәү сыйфатсыз эчә торган суны куллануны бетерү проблемаларының оператив хәл ителмәвенә китерә.

**2022-2024 елларда санитар-химик һәм микробиологик күрсәткечләр буенча гигиена таләпләренә җавап бирми торган бүлү челтәреннән су пробаларының чагыштырма авырлыгы.**

| Муниципаль район | санитар-химик күрсәткечләр буенча гигиена таләпләренә җавап бирми торган бүлү челтәреннән су пробаларының чагыштырма авырлыгы. | | | микробиологик күрсәткечләр буенча гигиена таләпләренә җавап бирми торган бүлү челтәреннән су пробаларының чагыштырма авырлыгы. | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | 2022 | 2023 | 2024 | 2022 | 2023 | 2024 |
| Алексеевск | 10,5 | 26,5 | 25,9 | 36,4 | 4,7 | 4,1 |
| Татарстан Республикасы | 5,9 | 6,7 | 8,3 | 2,8 | 1,8 | 2,3 |

Эчәргә яраклы су белән тәэмин итүнең сыйфаты буенча мәсьәләне штп Алексеевскта,Речное,Родники,Морд.Булак, Ивановский поселогы, Караваево,

Сахаровка, Шәмә, Сабакайка, Кыр Шонталысы торак пунктларында хәл итү зарур.

Чишмәләрдән алынган суны Ивановский поселогында, Родники, Морд. Булак та яшәүчеләр су үткәргеч челтәрендәге суның санитар-химик күрсәткечләр буенча гигиена таләпләренә туры килмәве аркасында файдаланырга мәҗбүр (югары катылык, тимер). Шулай ук тимернең күп булуы (гигиена нормасы 0,3мг/дм3 булганда фактик эчтәлеге 1,5мг/дм3 га кадәр) аркасында Алексеевск бистәсендә яшәүчеләр чистарту системаларыннан, якындагы чишмә суыннан, (Биләр, Красный Баран һ.б) файдаланалар.

2024 елда Алексеевск ш.т.п буенча үзәкләштерелгән эчәр су белән тәэмин итүнең җир асты чыганакларының торышы һәм су алу урыннарының су сыйфаты белән бәйле вәзгыять өлешчә үзгәрде. 2024 елның 2 яртыеллыгында һәм 2025 елның I кварталында су чистарту станциясен файдалануга тапшыру белән бәйле рәвештә мониторинглана торган нокталардан (бу бердәм су җыю урынындагы һәм Алексеевск ш.т. п. ндагы кран) суның сыйфаты яхшыру күзәтелә.

Химик состав буенча (гомуми катылык, тимернең күп булуы) гигиена нормаларының артуы җир асты суларының табигый составы белән аңлатыла. Эчәргә яраклы су белән тәэмин итү чыганакларының гомуми минеральләштерү яки тимернең күп булуы буенча нормативларга туры килмәве, йомшарту, тимерсезләндерү җайланмалары белән җиһазландырылмаган булуында.

**2019-2021 елларда Алексеевск районын үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү чыганакларында эчә торган суны лаборатор тикшерү**

| | 2019 | | | 2020 | | | 2021 | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Барлыгы сынаулар тикшерелде | гигиена нормаларына җавап бирми. | стандарт булмаган проблар % | Барлыгы сынаулар тикшерелде | гигиена нормаларына җавап бирми. | стандарт булмаган проблар % | Барлыгы сынаулар тикшерелде | гигиена нормаларына җавап бирми. | стандарт булмаган проблар % |
| **Микробиологик күрсәткечләр буенча** | | | | | | | | | |
| Үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү чыганакларыннан | 43 | 0 | 0 | 43 | 0 | 0 | 37 | 1 | 2,7 |
| **Санитар-химик күрсәткечләр буенча** | | | | | | | | | |
| Үзәкләштерелгән су белән | 50 | 7 | 14 | 57 | 24 | 42,1 | 53 | 7 | 13,2 |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| тәэмин итү чыганак ларын нан | | | | | | | | | |

Районда барлыгы 87 чыганак, шул исәптән 1 «Бердәм» су алу җайланмасы Алексеевск ш.т. п. халкын эчә торган су белән тәэмин итә.

«Алексеевск Водоканал» ААҖ гарантияле оешмасы бөтен районны диярлек эчә торган су белән тәэмин итә. Урта Тигәнәле, Түбән Тигәнәле, Юеш Көрнәле, Бутлеровка, Ивановский поселогы, Городок авылларын су белән тәэмин итү хуҗалык итүче субъектлар «Алга» колхозы һәм «Родина»колхозы артезиан скважиналарыннан башкарыла.

Шуны билгеләп үтәсе килә,Биләр тарихи–археологик табигать тыюлыгы территориясендә урнашкан «Изге чишмә» чишмәсеннән суны район халкы һәм Татарстан Республикасының башка районнарында яшәүчеләр экскурсия һәм дини максатларда булганда,эчә торган су чыганагы буларак кулланар.

## 1.6. Тормыш дәрәҗәсе

Халыкның яшәү дәрәҗәсен күп факторлар билгели: уртача хезмәт хакы, җан башына туры килгән керем, минималь куллану бюджеты, торак шартлары, гомер озынлыгы, сабыйлар үлеме дәрәҗәсе һ.б. Кайберләрен карарбыз.

### 1.6.1. Физик культура белән шөгыльләнү мөмкинлеге

| Еллар | Физкультура һәм спорт белән шөгыльләнүчеләр саны (кеше) | район халкы санына карата % |
|---|---|---|
| 2022 | 12 752 | 54,6 |
| 2023 | 12 755 | 55,2 |
| 2024 | 13 094 | 57,2 |

### 1.6.2. Сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру.

Гаиләнең социаль ролен күтәрү, физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру, буш вакытны рациональ файдалану эчкечелектән, наркоманиядән, иҗтимагый күренешләрдән ышанычлы саклану, киләчәк буыннарның сәламәтлеген формалаштыруның мөһим факторы булып тора. Спорт белән шөгыльләнүгә күбрәк кешеләрне җәлеп итү өчен төрле массакүләм чаралар үткәрелә.

Район халкының сәламәтлеген саклау системасында физик культура һәм спорт алыштыргысыз булып тора. Массакүләм физкультура һәм спортны оештыру өчен зур капитал салулар таләп ителми. Барлык оешма җитәкчеләренең бурычы физкультураны пропагандалаудан һәм массакүләм спортны үстерү өчен минималь шартлар тудырудан гыйбарәт. Балалар учреждениеләренә,

мәктәпләргә, тармак технологияләре техникумына массакүләм физкультура системасын кертү, район оешмаларында һәм предприятиеләрендә физик культура белән шөгыльләнүне активлаштыру зур әһәмияткә ия.

Сәламәт яшәү рәвеше алып баручы, спорт секцияләренә йөреп, физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүче оешмалар һәм предприятиеләр хезмәткәрләре саны елдан-ел арта бара.

Соңгы елларда спорт-сәламәтләндерү чаралары, физик культура һәм спорт белән район халкының 57% ы шөгыльләнә, шул ук вакытта икътисади яктан алга киткән илләрдә бу күрсәткеч 55% ка җитә.

Балалар һәм яшьләрнең спорт белән шөгыльләнүгә кызыксынуларын максатчан рәвештә сакларга, районның өстенлекле спорт төрләрендә традицияләрен ныгытырга кирәк.

## 2. Программаның төп юнәлешләре.

### 2.1. Гаилә белән яшәү рәвешен популярлаштыру.

Хәзерге вакытта җәмгыятьтә, бигрәк тә яшь буын вәкилләренең аңында, гаиләне мөһим социаль институт буларак, җенесләр арасында мөнәсәбәтләрнең югары эволюцион формасы һәм бер үк вакытта сәламәт балалар тудыру һәм тәрбияләү өчен кирәкле атрибут буларак аңлау аеруча мөһим. Гаиләгә ярдәм итүнең төп юнәлешләре булып тора:

- ныклы гаилә мөнәсәбәтләре идеологиясен формалаштыру, балалы гаиләләрне пропагандалау, гаилә ориентирларын һәм мәнфәгатьләрен үстерүгә ярдәм итү;

-- беренче никахта торучы , ике ата-анасы булган гаиләнең өстенлеген ныгыту, аларның репродуктив ориентациясен ике, өч балалы гаиләгә киңәйтү;

- балаларны, яшүсмерләрне һәм яшьләрне гаилә тормышына әзерләү системасы аша гаилә-юнәлешле шәхес формалаштыру, социализациянең төп субъекты буларак гаиләнең тәрбия потенциалын күтәрү;

- комплекслы медицина, социаль, психологик, яшь гаиләләргә дәүләт ярдәме күрсәтү;

- гражданлык никахлары санының алга таба үсешенә комачаулау;

- күп балалы һәм тулы булмаган гаиләләргә ярдәм итү системасын алга таба камилләштерү;

- балаларны һәм яшүсмерләрне гаилә тормышына әзерләүне өстәмә белем бирү системасына кертү: рухи-әхлакый кыйммәтләр, гаилә кыйммәтләре, берничә бала белән рәсми рәвештә теркәлгән никах, сәламәт яшәү рәвеше формалаштыру.

### 2.2. Халыкның сәламәтлеген яхшырту һәм үлемнәр санын киметү проблемаларын хәл итүне медицина белән тәэмин итү.

Максаты-тормыш дәрәҗәсен тотрыклы күтәрү, сәламәтлек саклауны үстерү, халыкны деалкоголизацияләү, хезмәтне саклау буенча чаралар ярдәмендә халыкның үлем санын киметү һәм социаль ярдәм чараларын камилләштерү буенча эзлекле сәясәт уздыру.

Бурычлар:

-Алексеевск муниципаль районында уртача гомер озынлыгын арттыру һәм үлем дәрәҗәсен киметү өчен иң уңайлы социаль-икътисадый климат булдыру;

- халыкның эзлекле рәвештә авырулар дәрәҗәсе кимүе;

- район предприятиеләрендә хезмәт шартларын яхшыртуга, хезмәтне саклауга, производствода имгәнүләрне, һөнәри авыруларны булдырмауга юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыру;

- юл-транспорт һәлакәтләре нәтиҗәсендә халыкның үлем санын киметү, сәламәтлекне яхшырту, өлкән яшьтәге гражданнар һәм инвалидлар арасында авыруларны профилактикалау системасының нәтиҗәлелеген арттыру, өлкән яшьтәге кешеләрне һәм инвалидларны медик-социаль һәм социаль-психологик тернәкләндерү системасын камилләштерү.

## 2.3. Сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру.

Максат-сәламәт халыкны яңадан формалаштыру, туганнан алып һәм гомер буе кешеләрнең сәламәтлеге турында кайгырту.

Бурычлар:

- сәламәтлекне ныгыту, эшкә сәләтлелекне, халыкның гомер озынлыгын арттыру, сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру өчен мөһим ресурс буларак физик культура һәм спортны үстерү;

- сәламәт яшәү рәвешен формалаштыруны, гаилә спортын үстерүне тәэмин итә торган структура буларак гаилә ролен пропагандалау;

- барлык хезмәт коллективларында, уку йортларында һәм гомумән районда сәламәт әхлакый-психологик климат булдыру;

- уку процессын оештыруны камилләштерү, туклануны һәм медик-санитар шартларны яхшырту, укучыларның сәламәтлеген һәм физик үсешен ныгыту өчен уңай шартлар тудыру;

- сәламәт яшәү рәвеше культурасын тәрбияләү, үз сәламәтлегеңне кайгырту зарурлыгына юнәлдерелгән иҗтимагый фикер формалаштыру;

- халыкның массакүләм физик культурасын оештыру;

- физик культура һәм спортның матди базасын алга таба ныгыту.

## 3. Көтелгән нәтиҗәләр.

«Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының 2025-2030 елларга халыкның сәламәтлеген яхшырту һәм үлем очракларын киметү» муниципаль программасының көтелгән соңгы нәтиҗәләре:

- үлемнәр санын киметү;

- гомер озынлыгын арттыру;

- халык сәламәтлеге торышын яхшырту;

- туучылар санын арттыру.

**Алексеевск районы буенча 2025-2030 елларда үлүчеләр саны күрсәткечләре буенча максат (1000 кешегә)**

| Еллар | Үлүчеләр саны буенча максат | Район буенча үлемнәр |
|---|---|---|
| 2025 | 347 | 14,1 |
| 2026 | 340 | 14,1 |
| 2027 | 335 | 14,0 |
| 2028 | 331 | 14,0 |
| 2029 | 324 | 13,9 |
| 2030 | 320 | 13,9 |

**Алексеевск районы буенча көтелгән гомер озынлыгы (ел).**

| | | **2025** | **2026** | **2027** | **2028** | **2029** | **2030** |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Район | ир ат | 75,57 | 75,62 | 75,67 | 75,70 | 75,72 | 75,75 |
| | хатын-кыз | 75,57 | 75,62 | 75,67 | 75,70 | 75,72 | 75,75 |
| ТР | ир-ат | 75,80 | 75,81 | 75,87 | - | - | - |
| | хатын-кыз | 75,80 | 75,81 | 75,87 | - | - | - |

«Земский доктор» программасы ярдәмендә медицина ярдәме күрсәтү мөмкинлеге яхшыра, бер табибка йөкләнеш кими, чиратлар кими, кадрлар житмәү проблемасы хәл ителә.

**«Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының 2025-2030 елларга халыкның сәламәтлеген яхшырту һәм үлем очракларын киметү» муниципаль программасын үтәү барышында чаралар**

Мең.сум

| № | Чара исеме | Башкаручы | Башкару вакыты | Финанслау чыганагы | Башкару |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Халыкара гаилә көненә, Халыкара балаларны яклау көненә, Әниләр көненә багышланган чаралар үткәрү | Авыл жирлекләре башлыклары, мәдәният бүлеге, социаль яклау бүлеге, мәгариф бүлеге, яшьләр | 2025-2030 ел | таләп ителми | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | эшләре секторы, спорт бүлеге, ЗАГС бүлеге | | | |
| 2. | «Алтын туйларын» һәм «бриллиант туйларын» билгеләп үтүче гаиләләр өчен тантаналы чаралар оештыру | ЗАГС бүлеге, Авыл җирлекләре башлыклары | 2025-2030 ел | таләп ителми | |
| 3. | Мәктәпләрдә гаилә кыйммәтләренә, гаиләнең кеше тормышында тоткан роленә багышланган сыйныф сәгатьләре һәм тематик дәресләр үткәрү | Мәгариф бүлеге планы буенча | 2025-2030 ел | таләп ителми | |
| 4. | Фертиль яшьтәге хатын-кызларга профилактик тикшерүләр | «Алексеевск РҮХ»ДАССО | 2025-2030 ел | таләп ителми | |
| 5. | Җәмгыятьтә гаилә һәм бала тууның роленә дөрес ориентирларны формалаштыру буенча җенси үсеш һәм гинекология авыруларын кисәтү буенча яшүсмерләр арасында профилактик һәм агарту эшен (әңгәмәләр) оештыру. Наркомания, эчкечелек һәм тәмәке тартуны профилактикалау. | «Алексеевск РҮХ» ДАССО, Мәгариф бүлеге | даими | таләп ителми | |
| 6. | «Әниләр мәктәбе» | Алексеевск РҮХ»ДАССО | даими | таләп ителми | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | нең эше хатын-кызлар консультациясендә, амбулаториядә, ФАПларда. | | | | |
| 7. | Авыруларны профилактикалау мәсьәләләре буенча халыкны массакүләм мәгълүмат чараларыннан файдаланып мәгълүмати тәэмин итү | Алексеевск РҮХ» ДАССО, район газетасы «Заря», «Таң» | ай саен | таләп ителми | |
| 8. | Халыкны флюорография тикшерүе планы үтәлешенең 100% тәэмин итү.. | Алексеевск РҮХ»ДАССО, авыл җирлекләре башлыклары | 2025-2030 ел | МИБ | |
| 9. | Медицина хезмәтенең, социаль яклау органнарының, мәгарифнең, традицион конфессияләрнең, авыр тормыш хәлләренә эләккән затларны рухи реабилитацияләүне гамәлгә ашыручы иҗтимагый берләшмәләрнең үзара хезмәттәшлеге. | Алексеевск РҮХ»ДАССО, социаль яклау органнары, гомуми белем бирү оешмалары, мөхтәсиб, православие | 2025-2030 ел | таләп ителми | |
| 10. | «ДС-ИФА-HBsAg» реагентлар җыелмасын сатып алу гепатит В вирусының өске | Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты | 2025-2030 ел | район бюджеты 250,0 | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | антигенын ачыклау яки раслау өчен иммунофермент тест-системасы,диагностик җыелма. | | | | |
| 11. | Бөер җитешсезлеге булган авыруларны дәвалау урынына бару чыгымнарын компенсацияләү - гемодиализ (махсус аппарат, бөер эшчәнлеге җитешсезлеге булган пациентларга канны чистарту. Районда әлеге төр ярдәм алучы 11 кеше бар. Бу-мондый авыруларның тормыш сыйфаты һәм озынлыгы, шулай ук медицина ярдәме алу мөмкинлеге). | Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты | 2025 ел<br>2026 ел<br>2027 ел<br>2028 ел<br>2029 ел<br>2030 ел | 350,0<br>350,0<br>350,0<br>350,0<br>350,0<br>350,0<br>район бюджеты | |
| 12. | Медицина белгечләрен максатчан укытуга җибәрү | Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты, «Алексеевск РҮХ» ДАССО, Мәгариф бүлеге | 2025 – 2030 ел | кирәк булганда | |
| 13. | Халыкка артык массаның зыяны, бигрәк тә йөрәк - кан тамырлары | «Алексеевск РҮХ» ДАССО | даими | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | авырулары үсеше куркынычы турында мәгълүмат бирү | | | | |

**Башкарма комитетның Эшләр идарәчесе** **Г.Ә. Йосыпова**